Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәк Иле авыл җирлеге Советының илле икенче утырышы

Кибәк Иле авыл җирлеге Советы

**КАРАРЫ**

29 май, 2020 ел № 147

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 маендагы 13 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» гы карарына үзгәрешләр һәм төгәлләштерүләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы законының 26 статьясы нигезендә, йортларны файдалануга тапшыру һәм сүтү белән бәйле рәвештә, бермандатлы сайлау округларының расланган чикләре чикләрендә гамәлдәге схемасын төгәлләштерү максатларында, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге советы карар чыгарды:**

1. «Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кибәк Иле авыл җирлеге советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» 2015 елның 12 маендагы 13 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм төгәлләштерүләрне кертергә:

1.1. Карар һәм кушымта исемендә, шулай ук 1 пункт текстында «өченче чакырылыш» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Бермандатлы сайлау округлары тасвирламасын (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кибәк Иле авыл җирлеге Советы карарына кушымта 2015 елның 12 маендагы 13 номерлы Кибәк Иле бермандатлы сайлау округларына түбәндәге йортларны кертеп төгәлләштерергә:

а) Кибәк Иле № 1 бермандатлы сайлау округында Мәктәп урамы буенча 13 нче йортны төшереп калдырырга.

б) Кибәк Иле № 2 бермандатлы сайлау округында Тукай урамы буенча 10 нчы йортны төшереп калдырырга.

в) Кибәк Иле № 4 бермандатлы сайлау округында Бакча урамы буенча 6 нчы йортны төшереп калдырырга.

г) Кибәк Иле № 5 бермандатлы сайлау округына Нариманов урамы буенча 15 нче йортны кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кибәк Иле авыл җирлеге башлыгы И.М. Зиннуров